Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты
Аксубай муниципаль районы
Татарстан Республикасы

Карар

№5 2021 елның 9нче ноябре

“Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәт авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында”

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.
Карар итте:
1. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәт авылында Новостройка, Горький, Үзәк урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәт авылында Гагарин, Пушкин, Лашевка, Правобереңный яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
3.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:
1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Рус Кармәте авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Новостройки, Гагарин, Үзәк, Горький, Пушкин, Лашевка урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтү.
2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Рус Кармәте авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су башнясын монтажлау өчен килешү буенча товарлар, материаллар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру

-Рус Кармәте авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләү

"ӘЙЕ" " ЮК" "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

4. Җыеннар үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Рус Кармәте авылы, Новостройка урамы 29нчы йорт адресы буенча урнашкан Рус Кармәт авыл мәдәният йорты .

5. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

6. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

7. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров